**КОММУНИЗМ БАЙРАГЫ**

**КПССның Чистай шәһәр комитеты һәм хезмәт ияләре депутатларының шәһәр һәм район Советлары органы.**
№ 23 (2713)
Якшәмбе, 22 февраль 1959 ел

# Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтев

**Мирза Исмәгыйль** улы **Мәхмүтев** 1926 елда Мордва АССРның Лямбир районы Алтар авылында туган.

Ул 1942 елда Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд өлкәсен дә Заамин МТСында тракторчы булып эшли.

1944 елда иптәш Мәхмүтев Совет Армиясенә чакырыла. 1949 елда ул авиаме-ханиклар хәзерли торган хәрби училищены тәмамлап, авиация техникгы булып эшли.

1950 елдан 1955 елга кадәр иптәш Мәхмүтев чит ил телләре хәрби институтында укый, аны тәмам иткәннән соң хәрби частьта тәрҗемәче булып эшли,

1956 елда Совет Армиясеннән кайткач, иптәш Мәхмүтев В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында гарәп теле укыта. 1958 елдан — Татарстан АССР мәгариф министры.

Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтев 1953 елдан КПСС члены.

Иптәш Мәхмүтев «Сугышчан хезмәтләр өчен»,. «1941 — 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен», «Совет Армиясенә һәм Флотына XXX ел» медальләре белән бүләкләнгән.

Каргалы сайлау округы хезмәт ияләре Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтевне бер-тавыштан Татарстан АССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр,

Сайлаучы иптәшләр! 1959 елның 1 мартында —сайлаулар көнендә бердәм рәвештә Татарстан АССР Верховный Советына депутатлыкка кандидат иптәш Мәхмүтевкә тавыш бирегез!